**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2342**
**05.05.2022**

Башкарма комитетның 2009 елның 8 апрелендәге 1357 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә кайнатылмаган, аертылмаган сөтне агызып сату урыннары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 41 статьясындагы 11 өлешенең 4 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Кайнатылмаган, аертылмаган сөт сату турында» 2009 елның 8 апрелендәге 1357 номерлы карары белән (Башкарма комитетның 2021 елның 16 февралендәге 1040 номерлы, 2021 елның 6 августындагы 5205 номерлы карарлары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәрендә кайнатылмаган, аертылмаган сөтне агызып сату урыннары исемлегенә, түбәндәге эчтәлектәге 8.1, 13.1, 21 пунктлары өстәп, үзгәрешләр кертергә:

| | |
|---|---|
| 8.1. | 26/06 торак йорты районында, «ЕвроРемонт» компаниясе каршында, җәяүлеләр тротуары буйлап Тынычлык проспектына якынрак бетон мәйданчыкта |
| 13.1. | Мәскәү проспекты, 86/2 йорты, «Удачный» кибете янындагы бетон мәйданчыкта, 56/11 торак йорты каршында |
| 21. | Магистральная урамы буенча, «Закамье» күпләп сату базасына керә торган төп капка районында бетон мәйданчыкта |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны, аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов